# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Ютазы тракты (4нче йорт 14 нче йорт) урамы буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

14 ноябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 14 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында йомгаклау беркетмәсе төзелде: «Сез, 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән (Ютазы тракты урамы (4 йорт буенча 14 йорт) балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, 1 төркеме инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге формада белем алучы студентлардан, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән махсус хәрби операциягә киткән гаиләләрдән кала 5000,0 (биш мең ) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерерү белән ризамы?”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 10 кеше теркәлгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 10 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 10 халык җыенында катнашучы;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 халык җыенында катнашучы

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Ютазы тракты урамын буенча (4 нче йорттан 14 нче йортка кадәр) гражданнар җыены узган, аның нәтиҗәләре дөрес дип танырга.
2. «Сез, 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән (Ютазы тракты урамы (4 йорт буенча 14 йорт) балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, 1 төркеме инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге формада белем алучы студентлардан, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән

махсус хәрби операциягә киткән гаиләләрдән кала 5000,0 (биш мең ) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерерү белән ризамы?”

Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

"Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең Ютазы тракты урамы, 4 нче йорттан 14 нче йортка кадәр, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларны карап тоту (юлларга асфальт-бетон җәю, сатып алу, төяү, ташу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)" кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны, кабул ителгән көннән соң 2 көн эчендә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Л. Ф. Миндубаева